Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыены карары

2024 елның 23 ноябре №4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 18 яшькә җиткәннәрнең гомуми санынннан 30% тан артмаска тиешле кешеләр, 1 төркем инвалидлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1.торак пункт чикләрендә гомумкүләм файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Шөгер авылының Халиков урамы, Калинин урамы, Яшьләр урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, шартнамә буенча түләү); Иске Шөгер авылында юлларны кардан чистарту, юлларны грейдерлау);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Шөгер авылында юл кырыйларыннан чүп үләнен чабу (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Иске Шөгер авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру; Иске Шөгер авылында С. Садри урамындагы һәйкәл территориясендә чәчәкләр һәм куаклар утырту, кулдан үлән чаптыру; Иске Шөгер авылының Яшьләр урамындагы «Яшьлек» паркында үлән чабу, чәчәкләр, куаклар уттырту);

3) традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (Иске Шөгер авылы зираты территориясендәге корыган һәм чүп үләннәрен чаптыру, авария хәлендәге иске агачлар һәм куакларны кисү (килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет ур., 1 йорт, Совет ур., 3 йорт буенча балалар бакчасы бинасы, М. Җәлил урамы 33нче йорт янында, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова